Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

7 ноябрь, 2025 ел № 5

Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлегенең Княжа авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 134 номерлы (2021 елның 14 декабрендәге 32 номерлы карар редакциясендә) Татар Тау Иле авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлегенең Княжа авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыен билгеләргә.

2025 елның 21 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Химиклар урамындагы 3 нче йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2026 елда Княжа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын һәм мәктәп укучыларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;

- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татар Тау Иле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлеге башлыгы И.Р.Габдрахманов